СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-15-99

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-15-99

**КАРАР**

№23 «01» октябрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” " 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федералҗ Законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Актаныш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12, 80 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитетының «Референдум үткәрү инициативасы турында» гы 2019 елның 16 сентябрендәге №15 карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 сентябрендә кабул ителгән 20 санлы «Референдум үткәрү инициативасы турында" карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. 2019 елның 24 ноябренә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми саныннан 30 проценттан да артмаганда, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- оештыру ритуаль хезмәтләр һәм күмү урыннарын карап тору;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

- җирлек чикләрендә халыкны электр һәм су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру

**“ӘЙЕ “** **“ЮК”**

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт; Актаныш районы, Актаныш авылы, Юбилейная урамы, 4 нче йорт;Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 56а йорт адреслары буенча урнашкан Актаныш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм «Актаныш таңнары» газетасында бастырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Актаныш авыл җирлеге башлыгы Э.Н.Фәттахов